**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ШӘМБАЛЫКЧЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

**КАРАРЫ**

2019 ел, 17 октябрь №192

**Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Шәмбалыкчы авыл җирлеге Советының 2008 ел, 12 гыйнвар, 1/4 номерлы "Аерым нотариаль гамәлләр кылу буенча дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруда катнашу турында" карарына үзгәрешләр кертү турында**

"Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында Федераль законның 16.1 статьясына һәм нотариат турында Россия Федерациясе законнары нигезләренә үзгәрешләр кертү хакында" 2019 елның 26 июлендәге 226-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Шәмбалыкчы авыл җирлеге Уставына нигезләнеп Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Шәмбалыкчы авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Шәмбалыкчы авыл җирлеге Советының 2008 ел, 12 гыйнвар, 1/4 номерлы номерлы "Аерым нотариаль гамәлләр кылу буенча дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруда катнашу турында" карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Преамбуланы түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131 номерлы Федераль законның 20 статьясындагы 1 өлешенең 3 пункты, 4.1 статьясындагы 4.1 өлеше, Нотариат турында Россия Федерациясе законнары нигезләренең 1 һәм 37 статьяларына нигезләнеп Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Шәмбалыкчы авыл җирлегендә нотариус булмау сәбәпле, Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Шәмбалыкчы авыл җирлеге Советы карар итте:"

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар Рәсми порталында һәм Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Шәмбалыкчы авыл җирлеге Уставында каралган тәртип буенча авыл җирлегенең максус мәгълүмат стендларында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Шәмбалыкчы авыл җирлеге Башлыгына йөкләргә.

**Шәмбалыкчы авыл җирлеге Башлыгы –**
**Шәмбалыкчы авыл җирлеге Советы Рәисе Ф. Ф. Миңнуллин**